**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7254**
**10.08.2023**

Яр Чаллы шәһәре территориясендә гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын һәм башка объектларын булдыру һәм файдалануга даими әзерлек хәлендә тоту турында

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнар оборонасының сыену урыннарын һәм башка объектларын булдыру тәртибе турында» 1999 елның 29 ноябрендәге 1309 номерлы карары, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының «Тыныч вакытта гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын карап тоту һәм файдалану тәртибен раслау турында» 2005 елның 21 июлендәге 575 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы нигезендә, Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларының һәм башка объектларының сакланышын тәэмин итү һәм алардан рациональ файдалану, аларны файдалануга даими әзерлектә тоту максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре территориясендә гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын һәм башка объектларын булдыру һәм файдалануга даими әзерлек хәлендә тоту турында нигезләмәне кушымтада каралганча расларга.

2. Тәкъдим итәргә:

1) гражданнар оборонасы объектларына ия оешмалар җитәкчеләренә гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларының һәм башка объектларының сакланышын тәэмин итү эшен һәм аларның инженерлык системаларының ышанычлы эшен оештырырга;

2) Яр Чаллы шәһәре территориясендә торак йортлар белән идарә итү буенча үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы идарәче компанияләргә, оешмаларга һәм торак милекчеләре ширкәтләренә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итү өчен кирәкле хезмәтләрнең һәм эшләрнең минималь исемлеге һәм аларны күрсәтү һәм башкару тәртибе

турында» 2013 елның 3 апрелендәге 290 номерлы карары таләпләре нигезендә, мобилизация чорында һәм сугыш вакытында халыкны саклау өчен тирәндә урнашкан биналардан һәм җир асты киңлегенең башка корылмаларыннан файдаланырга һәм (яки) гражданнар оборонасының саклагыч корылмалары буларак яраклаштырырга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 10 августындагы
7254 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре территориясендә
гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын һәм башка объектларын
булдыру һәм файдалануга даими әзерлек хәлендә тоту турында
нигезләмә

1. Әлеге Яр Чаллы шәһәре территориясендә гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын һәм башка объектларын булдыру һәм файдалануга даими әзерлек хәлендә тоту турында нигезләмә «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнар оборонасының сыену урыннарын һәм башка объектларын булдыру тәртибе турында» 1999 елның 29 ноябрендәге 1309 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында нигезләмәне раслау турында» 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы карары, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының «Гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын эксплуатацияләү кагыйдәләрен раслау һәм гамәлгә кертү турында» 2002 елның 15 декабрендәге 583 номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының «Тыныч вакытта гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын карап тоту һәм файдалану тәртибен раслау турында» 2005 елның 21 июлендәге 575 номерлы боерыгы нигезендә эшләнде һәм тыныч вакытта, мобилизация чорында һәм сугыш вакытында гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын булдыру һәм саклап тоту кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнар оборонасы объектларына түбәндәгеләр керә:

1) гражданнар оборонасының саклагыч корылмасы (алга таба – ГО СК) халыкны, гражданнар оборонасы көчләренең шәхси составын, шулай ук гражданнар оборонасы техникасын һәм мөлкәтен дошман һөҗүме чаралары тәэсиреннән саклау өчен билгеләнгән махсус корылма. ГО СК сугыш вакытында, шулай ук тыныч вакыттагы гадәттән тыш хәлләрдә яшеренүчеләрне саклау өчен билгеләнгән. ГО СК яшеренүчеләрне атом-төш зарарлау чараларының турыдан-туры булмаган тәэсиреннән, шулай ук гадәти зарарлау чаралары тәэсиреннән саклауны тәэмин итәргә тиеш һәм тыныч вакытта хуҗалык ихтыяҗлары һәм халыкка хезмәт күрсәтү өчен файдаланылырга мөмкин;

2) махсуслаштырылган склад бүлмәсе (саклау урыны) – анда урнаштырылган гражданнар оборонасы мөлкәтен саклау һәм аны билгеләнгән тәртиптә бирү өчен билгеләнгән бүлмә;

3) санитар-юу пункты – кием, аяк киеме алыштыру, халыкны санитар эшкәртү, тире капламының радиоактив зарарлануын (пычрануын), индивидуаль саклану чараларын, кешеләрнең махсус һәм шәхси киемнәрен контрольдә тоту өчен билгеләнгән техник һәм матди чаралар, бүлмәләр комплексы;

4) киемнәрне зарарсызландыру станциясе – махсус кием, аяк киеме эшкәртү өчен, шулай ук киемнәргә саклагыч составлар сеңдерү өчен билгеләнгән бүлмәләр, техник һәм матди чаралар комплексы;

5) техниканы зарарсызландыру станциясе – транспортның хәрәкәт итүче составын махсус эшкәртү өчен билгеләнгән бүлмәләр, техник һәм матди чаралар комплексы;

6) гражданнар оборонасының башка объектлары – гражданнар оборонасы буенча чаралар үткәрүне тәэмин итү өчен, шул исәптән кешеләрне һәм хайваннарны санитар

эшкәртү, юлларны, биналарны һәм корылмаларны дезактивацияләү, киемнәрне, транспорт чараларын махсус эшкәртү һәм башка кичектергесез эшләр өчен билгеләнгән объектлар.

3. Санитар-юу пунктлары, киемнәрне һәм техниканы зарарсызландыру станцияләре һәм гражданнар оборонасының башка объектлары радиация, химик, биологик һәм медицина ягыннан саклау һәм халыкның беренче чиратта яшәешен тәэмин итү, кешеләрне һәм хайваннарны санитар чистарту, юлларны, биналарны һәм корылмаларны дезактивацияләү, киемнәрне һәм транспорт чараларын махсус эшкәртү өчен булдырыла.

4. ГО СК түбәндәгеләр керә:

1) сыену урыны – норматив вакыт дәвамында яшеренүчеләрне атом-төш һәм химик корал һәм гадәти зарарлау чараларының, бактерияле (биологик) чараларның зарарлаучы факторларының һәм потенциаль-куркыныч объектлардагы авария вакытында, шулай ук янгыннар вакытында югары температурадан һәм яна торган продуктлардан барлыкка килә торган авария-химик куркыныч матдәләрнең зарарлаучы концентрацияләренең исәпләнгән йогынтысыннан саклау өчен билгеләнгән ГО СК;

2) радиациягә каршы яшеренү урыны – җирлек радиоактив зарарланган (пычранган) вакытта, яшеренүчеләрне ионлаштыручы нурланыш тәэсиреннән саклау өчен билгеләнгән һәм норматив вакыт дәвамында яшеренүчеләрнең анда өзлексез булу мөмкинлеген бирә торган ГО СК;

3) яшеренү урыны – яшеренүчеләрне гадәти зарарлау чараларының фугаслы һәм ярчыклы тәэсиреннән, төзелеш конструкцияләренең ватыклары белән зарарлаудан, шулай ук төрле этажлы биналарның югарыда урнашкан этажлары конструкцияләренең җимерелүеннән саклау өчен билгеләнгән ГО СК.

5. Сыену урыннары булдырыла:

1) мобилизацион йөкләмәсе (заказы) булган һәм урнашу урынына бәйсез рәвештә, гражданнар оборонасы буенча аеруча мөһим категориягә кертелгән оешма хезмәткәрләренең сугыш вакытында сан буенча максималь эшләүче сменасы (алга таба – оешманың иң күп эшләүче сменасы) өчен, шулай ук гражданнар оборонасы буенча беренче яки икенче категориягә кертелгән һәм гражданнар оборонасы буенча төркемгә кертелгән территориядә урнашкан оешманың иң күп эшләүче сменасы өчен;

2) радиоактив зарарлану (пычрану) ихтималы булган зонадан тыш, гражданнар оборонасы буенча төркемгә кертелгән территориядә урнашкан сәламәтлек саклау учреждениесендәге транспортабель булмаган авырулар һәм аларга хезмәт күрсәтүче медицина персоналы өчен.

6. Радиациягә каршы яшеренү урыннары булдырыла:

1) гражданнар оборонасы төркеменә кертелгән территориядән читтә радиоактив зарарлану (пычрану) ихтималы булган зонада урнашкан, гражданнар оборонасы буенча беренче яки икенче категориягә кертелгән оешманың иң күп эшләүче сменасы өчен;

2) радиоактив заралану (пычрану) ихтималы булган зонада урнашкан сәламәтлек саклау учреждениесендәге транспортабель булмаган авырулар һәм аларга хезмәт күрсәтүче медицина персоналы өчен.

7. Яшеренү урыннары булдырыла:

1) радиоактив зарарлану (пычрану) ихтималы булган зонадан тыш, гражданнар оборонасы төркеменә кертелгән территориядән читтә гражданнар оборонасы буенча беренче яки икенче категориягә кертелгән оешманың иң күп эшләүче сменасы өчен;

2) радиоактив зарарлану (пычрану) ихтималы булган зонадан тыш, гражданнар оборонасы төркеменә кертелгән территориядә урнашкан сәламәтлек саклау учреждениесендәге транспортабель булмаган авырулар һәм аларга хезмәт күрсәтүче медицина персоналы өчен.

8. Мобилизация чорында һәм сугыш вакытында халыкны саклау өчен гамәлдәге ГО СК файдаланыла һәм (яки) тирәндә урнашкан биналар һәм җир асты киңлегенең башка корылмалары ГО СК буларак яраклаштырыла.

9. Куркынычсыз районнарда яшәүче шәһәр халкы һәм көчле җимерелүләр ихтималы булган, химик һәм радиацияле зарарлану (пычрану) һәм катастрофик су басу ихтималы булган зоналардан эвакуацияләнә торган халык мобилизация чорында һәм сугыш вакытында торак төзелеше районнарындагы тирәндә урнашкан биналарда һәм җир асты киңлегенең башка корылмаларында яшеренә.

10. Шәһәр территориясендә торак йортлар белән идарә итү буенча үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы идарәче компанияләр, оешмалар һәм торак милекчеләре ширкәтләре тирәндә урнашкан биналарны һәм җир асты киңлегенең башка корылмаларын, шулай ук гадәти зарарлау чараларының фугаслы һәм ярчыклы тәэсиреннән, шул исәптән төрле этажлы биналарның өске этажлары җимерелү нәтиҗәсендә төзелеш конструкцияләренең ватыклары белән зарарланудан халык өчен яшеренү урыны буларак, төрле билгеләнештәге биналарның һәм корылмаларның подвал, цоколь этажларын яраклаштыралар һәм файдалануны тәэмин итәләр.

11. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе идарәче компанияләр һәм торак милекчеләре ширкәтләре белән тирәндә урнашкан биналарны һәм җир асты киңлегенең башка корылмаларын, шулай ук гадәти зарарлау чараларының фугаслы һәм ярчыклы тәэсиреннән, шул исәптән төрле этажлы биналарның өске этажлары җимерелү нәтиҗәсендә төзелеш конструкцияләренең ватыклары белән зарарланудан халык өчен яшеренү урыны буларак, төрле билгеләнештәге биналарның һәм корылмаларның подвал, цоколь этажларын файдалану һәм яраклаштыру мәсьәләләре буенча үзара эшчәнлек оештыра.

12. Муниципаль берәмлек чикләрендә Башкарма комитет: гражданнар оборонасы объектларына гомуми ихтыяҗны билгели;

1) тыныч вакытта гамәлдәге гражданнар оборонасы объектларын булдыра, саклый һәм аларны файдалануга даими әзерлек хәлендә тота;

2) гражданнар оборонасы объектларын булдыруга һәм аларны файдалануга даими әзерлек хәлендә тотуга контрольне гамәлгә ашыра;

3) гражданнар оборонасының гамәлдәге һәм төзелә торган объектлары исәбен алып бара.

13. Оешмалар тыныч вакытта:

1) Башкарма комитет белән килештереп, гражданнар оборонасы объектларын булдыралар;

2) гражданнар оборонасының гамәлдәге объектларының сакланышын тәэмин итәләр, аларны файдалануга даими әзерлек хәлендә тоту буенча чаралар күрәләр;

3) гражданнар оборонасының гамәлдәге һәм төзелә торган объектлары исәбен алалар.

14. Мобилизация чорында һәм сугыш вакытында гражданнар оборонасы объектларын булдыру Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау планы нигезендә гамәлгә ашырыла.

15. Гражданнар оборонасы объектларын булдыру үз билгеләнеше буенча гражданнар оборонасы объектлары буларак файдаланылырга мөмкин булган гамәлдәге, реконструкцияләнә торган һәм яңа төзелә торган биналарны һәм корылмаларны яраклаштыру хисабына гамәлгә ашырыла. Гражданнар оборонасы объектлары сыйфатында шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклануны тәэмин итү өчен билгеләнгән объектлар файдаланылырга мөмкин.

16. Тыныч вакытта гражданнар оборонасы объектлары, аларны билгеләнгән срокларда билгеләнеше буенча файдалануга әзерлек хәленә китерү мөмкинлеген саклап, билгеләнгән тәртиптә икътисад һәм халыкка хезмәт күрсәтү мәнфәгатьләрендә, шулай ук халыкны табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр аркасында килеп чыккан зарарлау факторларыннан саклау өчен файдаланылырга мөмкин.

17. ГО СКны тыныч вакытта карап тоту биналарны һәм яшәешне тәэмин итү системалары җиһазларын билгеләнгән срокларда билгеләнеше буенча файдалануга күчерүгә аларның даими әзерлеген һәм сугыш вакытында да, тыныч вакыттагы гадәттән

тыш хәлләр шартларында да ГО СКда яшеренүчеләрнең иминлеге өчен кирәкле шартларны тәэмин итәргә тиеш. ГО СКны билгеләнеше буенча файдалануга әзерлектә тоту өчен, оешмаларда аларга хезмәт күрсәтү төркемнәре (звенолары) төзелә. Шул ук вакытта түбәндәгеләрнең сакланышын тәэмин итәргә кирәк:

1) тулаем алганда ГО СКның саклау үзлекләре, шулай ук аның аерым элементлары;

2) барлык ГО СК герметизациясе һәм гидроизоляциясе;

3) ГО СКның инженерлык-техник һәм махсус җиһазлары, элемтә һәм хәбәр итү чаралары.

18. ГО СКны тыныч вакытта карап тотканда тыела:

1) биналарны яңадан планлаштыру;

2) киртәләү конструкцияләрендә тишекләр яки уемнар урнаштыру;

3) герметизацияне һәм гидроизоляцияне бозу;

4) җиһазларны демонтажлау; биналарның эчке бизәлеше өчен янучан төзелеш материалларын куллану;

5) хәрәкәт итү юлларын, ГО СКга керү юлларын һәм аварияле чыгу юлларын каплау;

6) биналарның түшәмнәрен һәм стеналарын штукатурлау;

7) стеналарны керамик плитә белән тышлау;

8) тыгызлаучы резина детальләрне, резина амортизаторларны, сыгылмалы киҗе-мамык, резина сеңдерелгән һәм бөгелүчән резина ялгауларны, металл җиңсәләрне, җитештерүче завод исеме һәм инженерлык-техник һәм махсус җиһазларның техник мәгълүматлары булган табличкаларны буяу;

9) ГО СКга керү юлларына, аварияле чыгу юлларына һәм тышкы һава җыю һәм һава суыру җайланмаларына якын территориядә проект документларында каралганнан ким ераклыкта төзелеш.

19. Яшеренүчеләрне кабул итүгә ГО СКны әзерләү чорында, ләкин 6 сәгатьтән артмаган вакытта аларны демонтажлау мөмкинлеген исәпкә алып, ГО СК бүлмәләрендә янмый торган һәм токсинлы булмаган материаллардан җиңел сүтелә торган вакытлы бүлмә такталарын урнаштыру рөхсәт ителә.

20. ГО СКның инженерлык-техник һәм махсус җиһазларын, элемтә һәм хәбәр итү чараларын, төзек һәм билгеләнеше буенча файдалануга әзерлек хәлендә тотарга кирәк.

21. Инженерлык-техник һәм махсус җиһазларны, элемтә һәм хәбәр итү чараларын карап тоту, эксплуатацияләү, агымдагы һәм планлы ремонтлау техник документлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

22. Тыныч вакытта ГО СКның һава белән тәэмин итү системаларыннан файдалану чиста вентиляция режимы буенча гына рөхсәт ителә.

23. Тыныч вакытта ГО СКның түбәндәге инженерлык-техник һәм махсус җайланмалары элементларыннан файдалану тыела:

1) сакланган дизель электр станциясенең вентиляция системаларыннан;

2) фильтр-сеңдергечләрдән;

3) алгы фильтрлардан;

4) һаваны углерод окисеннан чистарту өчен фильтрлардан;

5) һаваны регенерацияләү чараларыннан;

6) чуерташлы һава чистарткычлардан;

7) фекалий җыю өчен аварияле резервуарлардан. Резервуарлардан чыга торган урыннарда эшермәләр ябык булырга тиеш.

24. Тыныч вакытта ГО СКдан файдаланганда кирәк:

1) биналарда температураны проект таләпләренә туры китереп сакларга; керү һәм аварияле чыгу урыннарын атмосфера явым-төшемнәреннән һәм җир өсте суларыннан саклауны тәэмин итәргә;

2) биналарны һәм яшәешне тәэмин итү системалары җиһазларын билгеләнгән кагыйдәләргә туры китереп буярга һәм ремонтларга; һаваны углерод окисеннан чистарту

өчен фильтрларга, регенерация җайланмаларына һәм сеңдергеч фильтрга кадәр һәм аннан соң урнаштырылган герметик клапаннарны ябарга һәм печатьләп куярга;

3) аварияле эчәргә яраклы су запасының басымлы савытларында су агымын, 2 тәүлек эчендә суны тулысынча алмашырлык итеп тәэмин итәргә;

4) эчәргә яраклы су өчен запас савытны техник яктан төзек итеп тотарга; ярдәмче бүлмәләрне, шулай ук хуҗалык максатларында файдаланылмый торган санузелларны ябарга һәм печатьләп куярга; дизель электр станцияләрен консервацияләргә;

5) ачыла торган саклагыч-герметик һәм герметик капкаларны һәм ишекләрне аскуймалар белән тәэмин итәргә.

25. ГО СКдан файдаланганда янгынга каршы таләпләрне үтәү өлешендә, тыныч вакытта ГО СК бүлмәләренең билгеләнешенә бәйле рәвештә, Россия Федерациясендә янгын куркынычсызлыгы таләпләренә таянырга кирәк.

26. ГО СКның төп бүлмәләреннән файдалану, гамәлдәге норматив документларның әлеге функциональ билгеләнештәге бүлмәләргә карата мәҗбүри таләпләрен үтәгәндә, түбәндәгеләр өчен рөхсәт ителә:

1) санитар-көнкүреш бүлмәләре;

2) мәдәни хезмәт күрсәтү бүлмәләре һәм уку дәресләре өчен бүлмәләр; кешеләр өчен куркыныч зарарлы сыеклыклар, парлар һәм газлар бүлеп чыгармый һәм табигый яктыртуны таләп итми торган технологик процесслар гамәлгә ашырыла торган җитештерү бүлмәләре;

3) технологик, транспорт һәм җәяүлеләр тоннельләре;

4) дежур электриклар, элемтәчеләр, ремонт бригадалары бүлмәләре; җиңел автомобильләр өчен гаражлар, автокарлар һәм автомобильләрнең җир асты стоянкалары;

5) янмый торган, шулай ук, автомат янгын сүндерү системасы булганда, яна торган материалларны саклау өчен склад бүлмәләре;

6) сәүдә һәм туклану бүлмәләре (кибетләр, ашханә заллары, буфетлар, кафелар, кабымлыклар һ.б.);

7) спорт бүлмәләре (ату тирлары һәм спорт дәресләре өчен заллар);

8) халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү бүлмәләре (ателье, мастерскойлар, кабул итү пунктлары һ.б.);

9) дәвалау учреждениеләренең өстәмә (ярдәмче) бүлмәләре.

27. Мөлкәтне урнаштыру һәм туплау, аларны тикшерү, ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү өчен ГО СКның инженерлык-техник җиһазына һәм техник бүлмәләргә даими ирекле керү мөмкинлеген тәэмин итүне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

28. Тыныч вакытта, санузел бүлмәләреннән тыш, ГО СКның фильтр-вентиляция бүлмәләре, санитария узеллары, саклана торган дизель электр станцияләре, электр щитлары, азык-төлек саклау бүлмәсе, суыртып агызу станциясе, баллон бүлмәсе, тамбур-шлюз, тамбурлар караган ярдәмче бүлмәләреннән файдалану тыела.

29. ГО СКның техник торышын бәяләү ел саен, махсус (чираттан тыш) тикшерүләр, техник торышны комплекслы бәяләү һәм инвентаризация вакытында гамәлгә ашырыла.

30. Ел саен һәм махсус тикшерүләр ГО СКдан эксплуатацияләүче оешма җитәкчесе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

31. Махсус тикшерүләр янгыннардан, җир тетрәүләрдән, давыллардан, көчле яңгырлардан һәм су басулардан соң үткәрелә.

32. ГО СКны тикшергәндә түбәндәгеләр бәяләнергә тиеш:

1) корылманың гомуми торышы һәм керү юлларының, аварияле чыгу юлларының, һава җыю һәм газ чыгару каналларының торышы;

2) ишекләрнең (капкаларның, тәрәзә капкачларының) һәм ныгытып ябу механизмнарының төзеклеге;

3) саклагыч җайланмаларның, вентиляция системаларының, су белән тәэмин итү, канализация, электр белән тәэмин итү, элемтә, автоматика һәм башка җиһазларның

төзеклеге; бүлмә мәйданнарыннан икътисад ихтыяҗлары һәм халыкка хезмәт күрсәтү өчен файдалану;

4) янгын сүндерү чаралары булу һәм аларның торышы;

5) проект документлары булу.

33. ГО СКның техник торышын комплекслы бәяләү ГО СКны эксплуатацияләүче оешма тарафыннан өч елга бер тапкыр үткәрелә.

34. Башкарма комитет ГО СКның техник торышын бәяләүне үткәрүнең перспектив планнарын төзи, шул ук вакытта түбәндәгеләр бәяләнә:

1) сыену урынының герметиклыгы;

2) инженерлык-техник җиһазларның һәм саклагыч җайланмаларының барлык системаларының эшкә сәләте;

3) саклагыч корылманы план нигезендә әзерлеккә китерү мөмкинлеге;

4) чиста вентиляция һәм фильтрлы вентиляция режимнары буенча эшнең техник торышын бәяләп, 6 сәгать дәвамында ГО СК режимында эксплуатацияләү;

5) проект документлары булу.

35. Тирәндә урнашкан бүлмәләргә һәм җир асты киңлегенең башка корылмаларына комплекслы тикшерүләр үткәрү өчен, тикшерелә торган җиһазның сыйфатлы торышын билгеләп һәм аны алга таба билгеләнеше буенча файдалану буенча рекомендацияләр биреп бәяләмә бирергә тиешле һәм әлеге эшчәнлек төренә лицензиясе булган оешмалар җәлеп ителә.

36. ГО СКны эксплуатацияләүче оешмаларның гражданнар оборонасы җитәкчеләре ГО СКның техник торышын бәяләүне планлаштыралар һәм гамәлгә ашыралар.

37. ГО СКның техник торышын бәяләү нәтиҗәләре акт белән (әлеге нигезләмәгә 1 нче кушымта) рәсмиләштерелә. Төзелеш һәм киртәләү конструкцияләренең, техник системалар җиһазларының яки аларның аерым элементларының төзексезлеге һәм кимчелекләре ачыкланганда, кимчелекләр ведомосте (әлеге нигезләмәгә 2 нче кушымта) төзелә. Моннан тыш, ГО СКның техник торышын бәяләү барышында ачыкланган җитешсезлекләр, аларны бетерү буенча тәкъдимнәр ГО СКның техник торышын бәяләү журналында (әлеге нигезләмәгә 3 нче кушымта) чагылдырыла.

38. Акт һәм дефектлар ведомосте нигезендә техник чараларны һәм төзелеш конструкцияләрен планлы-кисәтү ремонтының еллык планнары төзелә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Яр Чаллы шәһәре территориясендә гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын һәм башка объектларын булдыру һәм файдалануга даими әзерлек хәлендә тоту турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

ГО саклагыч корылмасын карап тотуны
һәм файдалануны бәяләү
АКТЫ,
инв. № ________________

__________________________ шәһәре «______» _________________ 20 _____ ел

Комиссия түбәндәге составта: рәис ________________________ ________________________
(фамилия, и., а.и.) (вазыйфа)

комиссия әгъзалары
________________________ ________________________
(фамилия, и., а.и.) (вазыйфа)
________________________ ________________________
(фамилия, и., а.и.) (вазыйфа)
________________________ ________________________
(фамилия, и., а.и.) (вазыйфа)

__________________________________________________________ адресы буенча урнашкан, инв № ____________________ ГО саклагыч корылмасын карап тотуны һәм файдалануны тикшерде һәм саклагыч корылма ______ елда эксплуатациягә кабул ителүне һәм _____________________________ балансында торуны билгеләде.
Саклагыч корылма «______» _______________ 20____ елның № _________ шартнамә буенча ________________________________________________ арендага тапшырылды һәм ________________________________________ өчен файдаланыла.

1. Кирәкле документлар, саклагыч корылманы карап тоту өчен җаваплы зат һәм ГО СК хезмәт күрсәтү буенча төркем (звено) булу: ___________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

2. Вентиляция системасының торышы: ________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

3. Энергия белән тәэмин итү системасының торышы ______________________________

4. Су белән тәэмин системасының торышы: ______________________________

5. Канализация системасының торышы: ______________________________

6. Саклагыч корылманың гомуми торышы (конструкциясе, су үтү, герметиклык)

7. Карап тоту һәм файдалану буенча кимчелекләр: ______________________________

8. Комиссия нәтиҗәләре: ______________________________

9. Комиссия тәкъдимнәре: ______________________________

| | | |
|---|---|---|
| Комиссия рәисе: | ____________________ (имза) | ____________________ (фамилия, и., а.и.) |
| Комиссия әгъзалары: | ____________________ (имза) | ____________________ (фамилия, и., а.и.) |
| | ____________________ (имза) | ____________________ (фамилия, и., а.и.) |
| | ____________________ (имза) | ____________________ (фамилия, и., а.и.) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Акт белән таныштырылды: | ____________________ (вазыйфа) | __________ (имза) | ____________ (фамилия, и., а.и.) |
| Акт күчермәсе алынды: | ____________________ (вазыйфа) | __________ (имза) | ____________ (фамилия, и., а.и.) |

Искәрмә: әлеге акт ГО СК үзенчәлекләрен исәпкә алып тулыландырылырга мөмкин.

Яр Чаллы шәһәре территориясендә гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын һәм башка объектларын булдыру һәм файдалануга даими әзерлек хәлендә тоту турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

# ДЕФЕКТЛАР ВЕДОМОСТЕ

____________________________________________ тарафыннан тикшерелгән
(башкаручы оешманың исеме)
____________________________________________ җайланмага
(җайланманың төрен күрсәтергә)

| Җайланманың яки техник чараның исеме | Төзек булмаган узел яки деталь | Дефект | Бетерү ысулы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

НӘТИҖӘ:
Җайланмага ____________________________________ ремонт ясалырга тиеш.
(ремонт төрен күрсәтергә)

Башкаручы ____________________ ______________________________
(имза) (инициаллар, фамилия)

«____» ________________ 20____ел

Яр Чаллы шәһәре территориясендә гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын һәм башка объектларын булдыру һәм файдалануга даими әзерлек хәлендә тоту турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

ГО СК техник торышын бәяләү журналы
(форма)

______________________________________________________________
(ГО СК караган оешманың исеме)

_______________________________________________ адресы буенча урнашкан

| Техник торышны бәяләү датасы | Контрольдә тотучы затның вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары | Тикшерелгән конструкцияләр, узеллар, механизмнар һәм җайланмалар | Тикшерү нәтиҗәләре һәм ачыкланган җитешсезлекләр | Җитешсезлекләрне бетерү срогы | Җитешсезлекләрне бетерү датасы һәм җаваплы затның имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Искәрмә: журнал ГО СКда саклана.